**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2020 елның 15 июне** **№ 140**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында

2019 елның 12 ноябрендәге 367-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 10 сентябрендәге 44 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясындагы 3 пунктының, 86 статьясындагы 5 пунктының (бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләү сроклары өлешендә) гамәлдә булуын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Мәрәтхуҗа авылы, Ленин урамы, 61йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге Советы Рәисе Х.Х. Ибәтов